**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Кадер авыл җирлеге Советы**

# Карар

**№ 27** **24.07.2026**

**Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 29.12.2020 № 21 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Конкуренцияне яклау турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2025 елның 29 декабрендәге 577-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәме раслау хакында» 29.12.2020 № 21 карарына (Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының 20.04.2021 № 32, от 21.03.2022 № 57, от 28.11.2022 № 80, от 02.03.2023 № 96, от 30.10.2024 № 147, от 18.06.2025 № 180 карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.13. Шушы Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта аукцион җиңүчесе йә аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган зат белән сату-алу килешүе төзү "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта аукцион йомгаклары турында беркетмә урнаштырылган көннән алып ун көннән дә иртәрәк һәм егерме көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Муниципаль мөлкәтне җәмәгать сервитуты һәм (яки) 21.12.2001 № 178-ФЗ Федераль законда һәм (яки) башка федераль законнарда каралган чикләүләр белән йөкләгән очракта, аукционда төзелә торган мондый мөлкәтне сату-алу шартнамәсенең мөһим шарты булып сатып алучының әлеге йөкләмәнең шартларын үтәү бурычы тора.»;

1.2. 6.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.12. җәмәгать тәкъдиме ярдәмендә сатуда җиңүче белән сату-алу шартнамәсе төзү җәмәгать тәкъдиме ярдәмендә мөлкәтне сату йомгаклары турында беркетмә "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырылган көннән алып ун көннән дә иртәрәк һәм егерме көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **Л.Н. Барсукова**